Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № IX-3**

Балык Бистәсе штп. 2016 елның 4 марты

Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен җинаятьчел кул сузулардан яклау, җәмәгатьчелек ышанычын тәэмин итү һәм гражданнарга ярдәм итү буенча күрелә торган чаралар турында

Балык Бистәсе районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы, полиция полковнигы Р. Ф. Фәхретдинов мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү, җинаятьчел кул сузулардан гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, җәмәгатьчелек ышанычын тәэмин итү һәм гражданнарга ярдәм итү буенча күрелә торган чаралар буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге эшен оештыру турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлегенә тәкъдим итәргә:

2.1.оператив-эзләү чараларын үткәрүне дәвам итәргә:

-экстремистик эшчәнлекне кисәтү буенча;

- наркотиклар һәм коралның законсыз әйләнешен оештыруга катнашы булган затларга карата;

2.2.өстенлекле тәртиптә, коррупция юнәлешендәге җинаятьләрне ачыклау һәм булдырмау буенча тырышлыкларны туплап, бюджет акчаларын максатчан кулланмауга һәм урлауга бәйле җинаятьләрне чикләү һәм булдырмау эшен дәвам итәргә;

2.3.түбәндәге чараларны күрергә:

- Бердәм тавыш бирү көнен әзерләү һәм уздыру чорында районда оператив хәлне тотрыксызландыруны булдырмау;

-мәгариф оешмаларын террорчылыкка каршы һәм криминаль якланганлык предметына тикшерүләр үткәрү, алга таба башкарма хакимият органнарының ачыкланган җитешсезлекләре турында һәм әлеге

мәсьәләләрне хокук тәртибен тәэмин итү буенча даими эшләүче координация киңәшмәләрендә карау турында тәкъдимнәр кертү;

-тикшерүләре элек туктатылган җинаятьләрне ачу;

2.4 Балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны кисәтү, гаилә иминлеген, ятимлекне профилактикалау, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча эшне активлаштырырга;

2.5. Аеруча катлаулы булган урыннарда юл-патруль хезмәте нарядларының эшен һәм район юлларында юл-транспорт һәлакәтләрен киметүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашыруны оештырырга, аерым алганда - исерек хәлдә транспорт чаралары йөртүчеләр белән идарә итү буенча юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозучы нарядлар төркемнәре тарафыннан эшләнүне тәэмин итү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе                                        И.Г.Вәлиев